

4-6 мартта Казанда XII Ботенроссия татар авыллары эшмәкәрләре жыены vтте. Жыенда Россия Федерациясенен 44 тобәгеннән, 5 чит илдән барлыгы 800 татар эшмәкәре катнашкан.
*«ЭКО Халял» сэvдэ йорты директоры* **Талип Рафаил улы АБУБЕКИРОВ** ел саен Ботенроссия татар авыллары эшкуарлары жыенында катнаша. Ул жыен турындагы фикерен «Юлдаш» газетасы белән уртаклашты.
- Мордовиядән Ботенроссия татар авыллары эшмәкәрләре жыенында татар бизнесменнар клубы житәкчесе Гафур Галәв улы Абдрашитов житәкчелегендә 26 делегат катнашты, - ди Талип Рафаил улы.

- Казандагы жыен - Россиянен торле тобәкләреннән килгән татар авыллары эшкуарларынын бер-берсе белән тәжрибә туплау, vз эшчәнлекләре, авылда бизнес алып бару vзенчәлекләре, яшьләрне бу эшкә жәлеп итv тәжрибәсе турында сойләv момкинлеге булган мәйданчык, - дип сvзен дәвам итте әнгәмәдәшем. - Форумда бизнеска гына тvгел, милли мәдәниятне һәм телне саклауга һәм vстерvгә кагылышлы ин актуаль мәсьәләләр дә каралды.
Беренче конне жыен кысаларында дискуссия мәйданчыклары эшләде. Пленар утырыш алдыннан Россия Федерациясе тобәкләрендә житештерелгән продукция һәм халык кәсебе товарларыннан торган кvргәзмә-ярминкәсе белән танышырга момкинчелек тудырылган иде. Биредә Мордовиядән “Подлесная”, “ЭКО Халял”, “Карпайские”, “Юлдаш”, “Казы братьев Ишалеевых” сату маркалары житәкчеләре чыгыш ясадылар, торле тобәкләр белән элемтәләр урнаштырдылар. Мәсәлән, быел Мәскәv һәм Мәскәv олкәсе, Казахстан, Кыргызстан, Тюмень, Красноярск белән килешvләр тозелде.



Жыеннын икенче конендә, 5 мартта, “Корстон” сәvдә-кvнел ачу комплексында Татарстан Республикасы Рәисе Ростәм Миннеханов катнашында жыеннын пленар утырышы старт

алды. Ул: “Безнен нигезебез - авылда. 4200 гә якын татар авылы бар. Бу авылларнын эчтәлеге - эшмәкәрләрдә. Татарлыкка еш кына читтән торган татарлардан ойрәнергә кирәк. Алар халкыбызнын борынгыдан килгән һонәрчелек, кәсепчелектрадицияләрен дәвам иттерvче. Алар цехлар ача, эш урыннары булдыра, керемнәрен авылны саклауга юнәлтә. Алар vрнәгендә яшь буын тәрбияләнә һәм тора-бара vзләре дә авылны саклауга олеш кертә башлый. Әлбәттә, Ботендонья татарлар конгрессы сезгә таянып эшли. Һәрберегезгә зур рәхмәт!” - дип билгеләп vтте. ТР Рәисе Ростәм Миннеханов шулай ук Россия Федерациясенен Президентын сайлауларда актив катнашырга чакырды. Пленар утырышнын беренче олеше бvләкләv тантанасы белән тәмамланды. Чаранын икенче олешендә жыен кысаларында эшләгән дискуссия мәйданчыкларына нәтижә ясалды. Чара ахырында Татарстан Рес-публикасы Премьер-министры урынбасары, Ботендонья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Гаяз улы Шәйхразыев делегатларга Ботендонья татар конгрессы бv



ләкләрен тапшырды. Ирешкән унышлары очен Мордовиянен Ромодан районы Белозерье авылы эшмәкәре Юсеф Айса улы Асаиновка Рәхмәт хаты (Благодарственное письмо) тапшырды.
Жыенда катнашучылар очен кон мәдәни программа белән дәвам итте. В.И.Ленин исе-мендәге Мәдәни-ял итv комплексында Россиянен татар авыллары ассоциациясе рәисе, композитор, жырчы, шагыйрь Фәнир Галимов юбилеена багышланган ижат кичәсен карадык. Кичә кысаларында «Бабай утары» картиналар кvргәзмәсе дә тәкъдим ителде.
Алтынчы март коннәрендә XII Ботен-россия татар авыллары эшмәкәрләре жыены делегатлары Кукмара районында булдык. Кон дәвамында без бередәге татар авылларынын комплекслы vсеше белән таныштык һәм татар авыл эшмәкәрләренен хужалыкларын карадык.
Кукмара муниципаль районына барлыгы алты маршрут билгеләнгән иде. Бу районга бару очраклы тvгел, ул Татарстаннын алдынгы районнарынын берсе. Биредә “Адай икмәге”

икмәк пешерv цехын карадык, “Кукмара метал савыт-саба заводы”, итек комбинаты белән таныштык, Кукмара районынын Зур Сәрдек, Олыяз, Байлангар, Ядегәр авылында булдык. Сот продукциясен эшкәртv буенча да системалы эшлиләр. Мәсәлән, Ботендонья татар конгрессынын Башкарма комитеты житәкчесе Данис Шакиров Мордовия, Пенза, Пермь, Самара, Чувашстандагы зур татар авылларын да vрнәк итеп китерде.
Пленар утырышка кадәр делегатлар дvрт дискуссион мәйданчыкларда авыл хужалыгы продукциясен эшкәртv һәм сату мәсьәләләре, авылларны саклау һәм vстерvдә татар брендынын роле, авыл хужалыгы олкәсендә кадрлар әзерләv, игенчелек, терлекчелек тармагында инновацияләр турында фикер алыштык. Бу мәйданчыклар делегатларга vзара элемтәләр булдыру очен дә кирәк. Быелгы чаранын тагын бер яналыгы - Ботенроссия татар авыллары сабан туен оештырачак тобәктән ижат коллективлары, эшмәкәрләрдән торган аерым делегация чакырылып, алар vзләренен жирлекләре белән таныштырачак. Сvз унаеннан: быел татар авыллары Сабан туе Пермь краенын Барда районында узачак.
Без Ботендонья татар конгрессына, Татарстан Рәисе Ростәм Миннехановка, Кукмара районы житәкчелегенә рәхмәтләребезне житкердек.

**Наилә НАСЫРОВА**